# Иң яхшы библиотекага Татарстан хөкүмәте гранты

Бәзәкә авыл китапханәсенә (мөдире Бәшәрова Фәния Зиннәт кызы), Татарстан Республикасында авыл җирлекләрендәге иң яхшы муниципаль культура учреждениесе дип танылып, Татарстан хөкүмәтенең 100 000 сумлык гранты белән бүләкләнү уңаеннан котлауларыбызны җиткерәбез!
Афәрин, Фәния ханым! Бәзәкә халкы өчен зур, матур эшләр эшләп, янып яшәвегез өчен бик күп рәхмәтләребезне белдерәбез! Сезгә эшегездә яңадан яңа уңышлар, үзегезгә сәламәтлек телибез!



